# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Күгеш авыл җирлегенең Күгеш авылында
Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы

**2019 елның 10 декабре** **№ 6**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында " 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Күгеш авыл җирлегенең Күгеш авылында гражданнар җыены

**Карар итте:**

1. Күгеш авыл җирлегенең Күгеш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, Бөек Ватан сугышы ветераннары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан кала, 2020 елда 1000 сум күләмендә үзара салым акчасын кертергә .
2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- автомобиль юлларын ремонтлау һәм карап тоту, авыл җирлеге чикләрендәге җирлекне топографик төшерү, инерт материаллар сатып алу, шул исәптән объектларны техник паспортлаштыру ; ;
- территорияне пычрактан, чүп-чардан, кардан һәм боздан җыештыру, чүп-чар чыгару, каты көнкүреш калдыклары;
- ирекле янгын сүндерү сагы һәм махсуслаштырылган техниканы карап тоту, шул исәптән ягулык-майлау материаллары сатып алу;
- смета документациясен әзерләү, төзелеш контролен тормышка ашыру.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Күгеш авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе Ә. Ә. Гатауллин